РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» сентябрь 2021 ел г. Альметьевск № 31

Әлмәт шәһәре башкарма комитетының «Әлмәт шәһәренең топонимикасы буенча комиссия төзү турында» 2020 елның 15 декабрендәге 120 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2011 елның 22 сентябрендәге 37 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, урамнарга, мәйданнарга һәм территориянең башка состав өлешләренә исемнәр бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү тәртибен камилләштерү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәте рәисе урынбасары Т.А. Голикованың 2021 елның 30 июнендәге ТГ-П16-8721 күрсәтмәсен үтәү өчен,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт шәһәре башкарма комитетының «Әлмәт шәһәренең топонимикасы буенча комиссия төзү турында» 2020 елның 15 декабрендәге 120 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтада «комиссия секретаре, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча)» сүзләрен «комиссия секретаре, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты рәисе (килешү буенча)» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче кушымтаның 4 пунктын түбәндәге эчтәлекле 4.5 пунктча өстәргә:

«4.5. Урам-юл челтәре элементларына, планировка структурасы элементларына, шул исәптән географик объектларга, оешмаларга, учреждениеләргә һәм башка объектларга 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы геройлары хөрмәтенә исем биргәндә, 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы геройлары вафат булганнан соң исәпләнеп чыгарыла торган 3 елдан да артык булмаган (ул булган очракта) срокны түзәргә кирәк.».

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм

24 057

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косаревка йөкләргә.

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Р. Исхаков

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ